ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Новая, д.52, с.Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

# КАРАР

**«25» гыйнвар 2022 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә сафтан чыккан терекөмешле лампаларны туплау урынын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле калдыклар әйләнешен тәртипкә салу максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендэге 2314 номерлы карары белән расланган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләре нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучылырның (әлеге биналарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәсе яки мондый йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе төзелгән күпфатирлы йортларда биналар милекчеләре, яллаучылары, алардан файдаланучылар булган терекөмешле лампаларны кулланучылардан тыш) сафтан чыккан терекөмешле лампаларны туплау урыннары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Күпфатирлы йортларның милекчеләре белән төзелгән күпфатирлы йортлар белән идарә итү шартнамәсе яки мондый йортларда гомуми милекне

карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару шартнамәсе нигезендә терекөмешле лампалар кулланучы күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы юридик затларга (оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә) һәм шәхси эшмәкәрләргә сафтан чыккан терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыруны Кагыйдәләр нигезендә тәэмин итәргә.

3. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Кагыйдәләр нигезендә терекөмешле лампалар кулланучы юридик затларга (оештыру хокукый формасына бәйсез рәвештә) һәм шәхси эшмәкәрләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- сафтан чыккан терекөмешле лампаларны җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыруны оештыру буенча инструкцияләр эшләргә һәм әлеге калдыклар белән эш итү өчен җаваплы затларны билгеләргә;

-сафтан чыккан терекөмешле лампаларны җыю турында сафтан чыккан терекөмешле лампаларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру белән шөгыльләнүче, I - IV класслы куркынычлылык калдыкларын зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеген башкаруга лицензиясе булган юридик затлар яки шәхси эшмәкәрләр белән шартнамә төзергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Һидиятуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Иске Чүриле авыл җирлеге
Башкарма комитетының
"25" гыйнвар 2022 ел, № 1
карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә сафтан чыккан терекөмешле лампаларны туплау урыннары исемлеге**

| | |
|---|---|
| 1 | Сафтан чыккан терекөмешле лампаларны кабул итү пунктлары: Татарстан Республикасы, Арча районы, Иске Чүриле авылы, Новая урамы, 52 йорт |